# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Кулланучыларның хокукларын яклау турында

Әлеге Закон товарлар сатканда (эшләр башкарганда, хезмәт күрсәткәндә) кулланучылар белән әзерләүчеләр, башкаручылар, сатучылар арасында барлыкка килүче мөнәсәбәтләрне җайга сала, кулланучыларның тиешле сыйфатлы һәм кулланучылар гомере һәм сәламәтлеге өчен имин товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу һәм аларны сайлап алу, товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) һәм аларны әзерләүчеләр турында мәгълүмат алу, мәгърифәтле булу, үз мәнфәгатьләрен дәүләт һәм җәмәгатьчелек тарафыннан яклау хокукларын урнаштыра, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә әлеге хокукларны гамәлгә ашыруның механизмын федераль законнар нигезендә һәм шуларга туры китереп билгели.

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территорисендә эшчәнлек белән шөгыльләнүче барлык әзерләүчеләргә (башкаручыларга, сатучыларга) кагыла.

### 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

**1 статья.** Төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

кулланучы - табыш алу белән бәйләнмәгән, бары тик шәхси (көнкүреш) ихтыяҗлары өчен генә товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) заказ бирергә яисә сатып алырга җыенган яки аларга заказ биргән, аларны сатып алган яисә кулланган граждан ул;

әзерләүче - милек рәвешенә карамастан, кулланучыларга са-

ту өчен товарлар җитештерүче оешма, шулай ук индивидуаль эшкуар ул;

башкаручы - милек рәвешенә карамастан, түләүле шартнамә буенча кулланучылар өчен эшләр башкаручы яисә хезмәт күрсәтүче оешма, шулай ук индивидуаль эшкуар ул;

сатучы - милек рәвешенә карамастан, сату- алу шартнамәсе буенча кулланучыларга товарлар сатучы оешма, шулай ук индивидуаль эшкуар ул;

стандарт - товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфатына карата закон нигезендә мәҗбүри таләпләр билгеләүче дәүләт стандарты, санитар нормалар һәм кагыйдәләр, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре һәм башка документлар ул;

товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) җитешсезлеге - товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) стандартка, шартнамә шартларына яисә товар (эш, хезмәт күрсәтү) сыйфатына карата белдерелүче гадәти таләпләргә туры килмәве ул;

товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) асылый җитешсезлеге - товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) максатчан билгеләнеше буенча кулланылуы мөмкин булмауны яисә бетенләй рөхсәт ителмәүне, йә бу җитешсезлекне бетерергә мөмкин булмауны, йә бетергәннән соң да җитешсезлекнең яңадан килеп чыгуын, йә аны бетерү өчен бик күп чыгымнар кирәк булуны, йә шул җитешсезлек аркасында шартнамә төзегәндә кулланучы исәп тотканнан шактый дәрәҗәдә мәхрүм ителүне барлыкка китерүче җитешсезлек ул;

товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) иминлеге - аны куллануның, саклауның, транспортлауның һәм икенчел кулланылышка әзерләүнең гадәти шартларында кулланучының гомере, сәламәтлеге, милкәте өчен һәм әйләнә-тирә мохит өчен иминлеге, шулай ук эшне башкару (хезмәт күрсәтү) барышының имин булуы ул.

<u>2 статья.</u> Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау өлкәсен хокукый җайга салу

Татарстан Республикасында кулланучыларның хокукларын яклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләр гражданлык законнары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив-хокукый актлар белән җайга салына.

3 статья. Халыкара шартнамәләр

Әгәр Татарстан Республикасының халыкара шартнамәсендә кулланучыларның хокукларын яклау турында әлеге Законгагыдан үзгә кагыйдәләр билгеләнгән булса, халыкара шартнамә кагыйдәләре кулланыла.

4 статья. Кулланучыларның үз хокукларын яклау өлкәсендә мәгърифәткә хокукы

Кулланучыларның үз хокукларын яклау өлкәсендә мәгърифәткә хокукы дәүләт мәгариф стандартларына һәм гомуми белем, профессиональ белем программаларына тиешле таләпләр кертү юлы белән, шулай ук кулланучыларның хокуклары турындагы һәм әлеге хокукларны яклау буенча аларның зарури гамәлләре турындагы мәгълүматлар системасын оештыру юлы белән тәэмин ителә.

5 статья. Кулланучыларның хокукларын яклау турындагы законнарны өйрәнү буенча әзерләүчеләрнең (башкаручыларның, сатучыларның) бурычы

Әзерләүчеләр (башкаручылар, сатучылар) кулланучыларның хокукларын яклау турындагы законнарны белергә бурычлы.

6 статья. Кулланучыларның әзерләүче (башкаручы, сатучы) турында һәм товарлар (эшләр,хезмәт күрсәтүләр) турында мәгълүмат алу хокукы

1. Кулланучы әзерләүче (башкаручы, сатучы) турында, аның эш режимы һәм ул сатучы товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) турында мәгълүмат бирүне таләп итәргә хаклы.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат, күргәзмә һәм аңлаешлы рәвештә, сату-алу шартнамәләре һәм эшләр башкару (хезмәт күрсәтү) турында шартнамәләр төзелгәндә, кулланучыларга хезмәт күрсәтүнең аерым өлкәләрендә кабул ителгән ысуллар белән Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә җиткерелә.

272



7 статья. Әзерләүче (башкаручы, сатучы) турында мәгълүмат

1. Әзерләүче (башкаручы, сатучы) үз оешмасының фирма исемен (исемен), урнашкан җирен (юридик адресын) һәм үзенең эш режимын кулланучыга җиткерергә тиеш. Сатучы (башкаручы) әлеге мәгълүматны алтактада (вывескасында) урнаштыра.

Әзерләүче (башкаручы, сатучы) - индивидуаль эшкуар дәүләт теркәве һәм үзен теркәгән орган турындагы мәгълүматны кулланучыга тәкъдим итәргә тиеш.

2. Әгәр әзерләүче (башкаручы, сатучы) шөгыльләнә торган эшчәнлек төре (төрләре) лицензияләнергә тиеш булса, ул лицензия номеры, аның гамәлдә булу чоры турындагы мәгълүматны, шулай ук шушы лицензияне биргән орган турындагы мәгълүматны кулланучыга җиткерергә тиеш.

3. Вакытлы биналарда, ярминкәләрдә, лотоклардан сәүдә иткәндә, көнкүреш һәм бүтән төр хезмәт күрсәткәндә һәм сәүдә итү, көнкүреш һәм башка төр хезмәт күрсәтү өчен сатучының (башкаручының) даими урыны булмаган очракларда да әлеге статьяның 1 һәм 2 пунктларында каралган мәгълүмат кулланучыга җиткерелергә тиеш.

8 статья. Товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) турында мәгълүмат

1. Әзерләүче (башкаручы, сатучы) товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) турында аларны дөрес сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итәр өчен кирәкле һәм дөрес мәгълүматны кулланучыга үз вакытында бирергә бурычлы. Товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) аерым төрләре буенча исемлек һәм мәгълүматны кулланучыга җиткерү алымнары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

2. Товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) турындагы мәгълүматта мәҗбүри төстә түбәндәгеләр булырга тиеш:

товарлар (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) аның таләпләренә мәҗбүри туры килерлек стандартлар билгеләү;

товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) төп куллану сыйфатлары турындагы белешмәләр, ә азык-төлек продуктларына карата - азык-төлек продуктларының составы (шул исәптән әлеге

продуктны әзерләгәндә салынган башка продуктларның һәм башка өстәлмәләрнең составы) турында , авырлыгы һәм күләме турында, азык-төлек продуктларының калориялеге хакында, стандартларның мәҗбүри таләпләре белән чагыштырганда сәламәтлеккә зарарлы матдәләрнең булу-булмавы турында, шулай ук кайбер сырхаулар вакытында аларны кулланунын зарарлы булуы хакындагы белешмәләр. Аерым сырхаулар вакытында куллану зарарлы булган товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) исемлеге федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә раслана;

товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) бәясе һәм аларны сатып алу шартлары;

әлеге Закон нигезендә билгеләнгән булса, гарантия чоры;

товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) нәтиҗәле һәм хәвефсез куллануның кагыйдәләре һәм шартлары;

товарларның (эшләрнең) әлеге Законда билгеләнгән хезмәт итү чорын яисә гамәлгә яраклы чорын, шулай ук әлеге чор узганнан соң һәм шуның аркасында кулланучы сәламәтлегенә, гомеренә һәм мөлкәтенә куркыныч яналса яисә бу товарлар (эшләр) билгеләнеше буенча кулланырга яраксыз булса, кулланучының нинди гамәл кылырга тиешлеге турында һәм, шушы гамәлләрне кылмаганда, мөмкин булган нәтиҗәләр хакындагы белешмәләр;

әзерләүченең (башкаручының, сатучының) урнашкан җире (юридик адресы) һәм кулланучыларның дәгъваларын кабул итүгә ул вәкаләт биргән һәм товарны (эшне) ремонтлаучы һәм аларга техник хезмәт күрсәтүче оешманың (оешмаларның) урнашкан җире;

мәҗбүри рәвештә сертификацияләнергә тиешле товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) сертификациясе турындагы мәгълүмат;

товарларны сату (эшләрне башкару, хезмәт күрсәтү) кагыйдәләре турындагы мәгълүмат.

Әгәр кулланучы сатып ала торган товар әлегә кадәр кулланылгын булса яисә андагы җитешсезлек (җитешсезлекләр) төзәтелгән булса, кулланучыга бу хакта мәгълүмат бирелергә тиеш.

3. Әлеге статьяның икенче пунктында каралган мәгълүмат товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) кушымта итеп бирелүче техник документларда, этикеткаларда, маркировка рәвешендә яисә товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) кайбер төрләре өчен кабул ителгән башка алымнар белән кулланучыларга

җиткерелә. Товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) сертификациясе турындагы мәгълүмат билгеләнгән тәртиптә маркировка рәвешендә туры килү тамгасы белән һәм техник документларда сертификацияне үткәрү (сертификат номеры, аның гамәлдә булу чоры, аны биргән орган) турындагы белешмәләр рәвешендә күрсәтелә.

Татарстан Республикасы территориясендә төрелгән яисә бүлеп тутырылган азык-төлек продуктлары аларны әзерләүченең урнашкан җире хакындагы мәгълүмат белән тәэмин ителергә тиеш.

<u>9 статья.</u> Сатучының (әзерләүченең) эш режимы

1. Сәүдә, көнкүреш хезмәте һәм кулланучыларга башка төрле хезмәт күрсәтүче дәүләт (республика, коммуналь) оешмаларының эш режимы Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең республика һәм җирле органнары карары буенча билгеләнә.

2. Сәүдә, көнкүреш хезмәте һәм кулланучыларга башка төрле хезмәт күрсәтүче өлкәләрдәге эшчәнлек белән шөгыльләнүче һәм әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән оешмаларның, шулай ук индивидуаль эшкуарларның эш режимы алар тарафыннан мөстәкыйль рәвештә билгеләнә.

3. Сатучының (башкаручының) эш режимы кулланучыларга җиткерелә һәм билгеләнгән режимга туры килергә тиеш.

4. Кулланучы сатучының (әзерләүченең) эш режимы билгеләнгән режимга туры килүне таләп итәргә хаклы.

<u>10 статья.</u> Товар (эш, хезмәт күрсәтү) турындагы, әзерләүче (башкаручы, сатучы) турындагы тиешле мәгълүмат бирмәгән өчен әзерләүченең (башкаручының, сатучының) җаваплылыгы

1. Әгәр товар (эш, хезмәт күрсәтү) турында, шулай ук әзерләүче (башкаручы, сатучы) хакында гамәлгә яраксыз, ягъни дөрес булмаган яисә җитәрлек дәрәҗәдә тулы булмаган мәгълүмат бирелсә, ул түбәндәгеләргә китерә:

кулланучыга кирәкле сыйфатлары булмаган товар (эш, хезмәт күрсәтү) сатып алынганда, кулланучы килешүдән баш тартырга һәм китерелгән зыянны тулысынча түләтергә хаклы. Бу вакытта кулла-

нучы товарны (башкарылган эшне) әзерләүчегә (башкаручыга, сатучыга) кире кайтарып бирергә тиеш;

сатып алынган товарны (эшне, хезмәт күрсәтүне) билгеләнеше буенча куллану мөмкин булмаса, кулланучы акылга муафыйк вакыт эчендә тиешле мәгълүмат соратып алырга хаклы. Әгәр мәгълүмат сөйләшенгән вакыт эчендә бирелмәсә, кулланучы килешүне өзәргә һәм китерелгән зыянны тулысынча түләтергә хаклы. Бу очракта кулланучы товарны (башкарылган эшне) әзерләүчесенә (башкаручыга, сатучыга) кире кайтарып бирергә тиеш;

кулланучыга тапшырганнан соң товарның (эшнең) җитешсезлекләре килеп чыкса, кулланучы сатучыга (әзерләүчегә) әлеге Законның 20 статьясындагы 1-4 пунктларда яисә әлеге Законның 31 статьясындагы 1 пунктта каралган таләпләрне куярга хаклы;

кулланучының гомеренә, сәламәтлегенә яисә милкәтенә зарар китерелсә, ул әзерләүчедән (башкаручыдан, сатучыдан) китерелгән зыянны әлеге Законның 16 статьясында каралган тәртиптә түләтергә, шулай ук кулланучы милкендә булган табигать объектларына китерелгән зыянны тулысынча түләүне таләп итәргә хаклы.

2. Товар (эш, хезмәт күрсәтү) турында дөрес булмаган яисә җитәрлек тулы булмаган мәгълүмат аркасында китерелгән зыяннарны түләттерү хакында кулланучы таләпләрен карaганда, товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) сыйфатлары һәм сыйфатламалары турында кулланучының махсус белеме булмауны күз алдында тотарга кирәк.

<u>11 статья.</u> Товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) сыйфаты

1. Сатучы (әзерләүче) кулланучыга сыйфаты шартнамәгә туры килерлек товар тапшырырга (эш башкарырга , хезмәт күрсәтергә) тиеш.

2. Шартнамәдә товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) сыйфаты турындагы шартлар булмаганда, сатучы (әзерләүче) кулланучыга товар (эш, хезмәт күрсәтү) гадәттә кулланыла торган максатлар өчен яраклы товар (эш, хезмәт күрсәтү) тапшырырга тиеш.

3. Әгәр сатучыга (башкаручыга) кулланучы шартнамә төзегәндә товарны сатып алу (эшне башкару, хезмәт күрсәтү) максатлары турында хәбәр иткән булса, сатучы (башкаручы) кулланучыга

әлеге максатларда куллану өчен яраклы товарны тапшырырга (эш башкарырга, хезмәт күрсәтергә) тиеш.

4. Үрнәге һәм (яисә) язмача сыйфатламасы буенча товар сатканда сатучы кулланучыга үрнәгенә һәм (яисә) сыйфатламасына туры килерлек товар тапшырырга тиеш.

5. Әгәр стандартта товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) сыйфатына карата мәҗбүри таләпләр каралган булса, сатучы (әзерләүче) кулланучыга шушы таләпләргә туры килерлек товар тапшырырга (эш башкарырга, хезмәт күрсәтергә) тиеш.

<u>12 статья.</u> Әзерләүченең (башкаручының, сатучының) товарның (эшнең) хезмәт итү чорын, гамәлгә яраклылык вакытын, шулай ук товарга (эшкә) гарантия чорын билгеләү өлкәсендәге хокуклары һәм бурычлары

Озак вакытлар куллану өчен билгеләнгән товарга (эшкә) карата әзерләүче (башкаручы) хезмәт итү чорын - әзерләүче (башкаручы) кулланучының товарны (эшне) билгеләнеше буенча куллану мөмкинлеген тәэмин итәргә һәм аның гаебе белән килеп чыккан җитешсезлекләр өчен җаваплы булырга тиешле вакытны урнаштырырга хаклы.

2.Әзерләүче (башкаручы) озак вакытлар куллану өчен билгеләнгән товарның (эшнең), шул исәптән куллануның билгеле бер дәвере узгач кулланучы гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә, әйләнә-тирә табигать мохитенә куркыныч тудырырлык комплектлаучы әйберләрнең (детальләрнең, буыннарның, агрегатларның) хезмәт итү чорын билгеләргә тиеш. Мондый товарларның (эшләрнең) исемлеге законнарда билгеләнгән тәртиптә раслана.

3. Товарның (эшнең) хезмәт итү чоры вакыт берәмлекләре, шулай ук башка берәмлекләр (километрлар, метрлар һәм башка шундыйлар) белән исәпләнә.

4. Азык-төлек продуктларына, парфюмерия-косметика товарларына, медикаментларга, көнкүреш химиясе товарларына һәм башка шундый товарларга (эшләргә) әзерләүче (башкаручы) товарның яраклы булу чорын - куллану өчен билгеләнгән вакыты узгач товарның (эшнең) яраксызга чыгу чорын билгеләргә тиеш. Мондый товарларның (эшләрнең) исемлеген Татарстан Республикасы Ми-

нистрлар кабинеты законнарда билгеләнгән тәртиптә раслый.

5. Хезмәт итү чоры узган товарны (эш башкаруны), шулай ук хезмәт итү һәм яраклылык чоры билгеләнергә тиеш булып та, бу вакыт билгеләнмәгән товарны сату (эшне башкару) тыела.

6. Әзерләүче (башкаручы) товарга (эшкә) гарантия чоры билгеләргә хаклы - товарның (эшнең) җитешсезлеге мәгълүм булган очракта, әзерләүче (башкаручы, сатучы) кулланучының әлеге Законның 20 һәм 31 статьяларында билгеләнгән таләпләрен канәгатьләндерергә тиеш.

7. Сатучы товарга әзерләүче (башкаручы, сатучы) билгеләгән гарантия чорыннан тыш өстәмә гарантия чоры билгеләргә хаклы яисә, әзерләүче гарантия чоры билгеләмәгән булса, сатучы әлеге Законның 21 статьясындагы 1 пунктның икенче абзацында каралган вакыттан тыш гарантия чоры билгели ала.

Кулланучы сатып алган товарында сатучы билгеләгән гарантия чоры дәвамында җитешсезлекләр ачыклаган очракта, сатучыга карата таләпләр куярга хаклы, мондый таләпләрне канәгатьләндерү тәртибе һәм вакыты, шулай ук сатучының җаваплылыгы кулланучы белән сатучы арасында төзелгән шартнамәдә билгеләнә.

13 статья. Әзерләүченең товарны ремонтлау һәм аңа техник хезмәт күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итү буенча бурычы

Әзерләүче товарның хезмәт итү чоры дәвамында аны куллану мөмкинлеген тәэмин итәргә бурычлы. Бу максат өчен әзерләүче товарны ремонтлауны һәм аңа техник хезмәт күрсәтүне, шулай ук товарны җитештерү чорында һәм аны җитештерүдән төшереп калдыргannan соң да товарның хезмәт итү чоры дәвамында, ә андый вакыт билгеләнмәгән булса, кулланучыга товар сатылган көннән алып ун ел эчендә шушы товарны ремонтлау һәм аңа техник хезмәт күрсәтү өчен кирәкле күләмдә һәм ассортиментта запас частьләрне чыгаруны һәм аларны сәүдә, ремонт оешмаларына җиткерүне тәэмин итә.

14 статья. Кулланучының товар (эш, хезмәт күрсәтү) хәвефсезлегенә хокукы

1. Кулланучы товарны (эшне, хезмәт күрсәтүне) гадәти шартларда куллануның, саклауның, транспортлау һәм икенчел файдалануның үз гомере, сәламәтлеге һәм әйләнә-тирә мохит өчен хәвефсез булуын һәм шулай ук мөлкәтенә зарар китермәүне таләп итәргә хокуклы.

Товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) кулланучы гомеренә һәм сәламәтлегенә карата иминлеген һәм мөлкәтенә зарар китермәвен тәэмин итәргә тиешле таләпләр мәҗбүри булырга тиеш һәм алар законда билгеләнгән тәртиптә урнаштырылалар.

2. Әзерләүче (башкаручы) товарның (эшнең) хезмәт итү чорында яисә товарның (эшнең) яраклылык чорында билгеләнгән хәвефсезлеген тәэмин итәргә тиеш.

Әгәр әлеге Законның 12 статьясындагы 1 пункт нигезендә әзерләүче (башкаручы) товарның (эшнең) хезмәт итү чорын билгеләмәгән булса, ул товарны (эшне) кулланучыга саткан көннән алып ун ел дәвамында товарның (эшнең) иминлеген тәэмин итәргә тиеш.

Кулланучының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә товарның (эшнең) иминлеген тәэмин итмәү аркасында китерелгән зарар әлеге Законның 16 статьясы нигезендә түләттерелә.

3. Әгәр товарны (эшне, хезмәт күрсәтүне) имин куллануның, саклауның, транспортлауның һәм икенчел файдалануның махсус кагыйдәләрен (алга таба - кагыйдәләрен) үтәргә кирәк булса, әзерләүче (башкаручы) товарга (эшкә, хезмәт күрсәтүгә) өстәп бирелүче документларда, товарның этикеткасында, маркировка рәвешендә яисә башка алымнар белән күрсәтергә тиеш, ә сатучы (әзерләүче) исә бу кагыйдәләрне кулланучыга җиткерергә тиеш.

4. Законнарда яисә стандартларда товарга (эшкә, хезмәт күрсәтүгә) кулланучы гомеренә, сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә карата иминлекне һәм кулланучының мөлкәтенә зарар китерелмәүне тәэмин итәрлек таләпләр билгеләнгән икән, бу таләпләр, шулай ук кулланучы гомеренең һәм сәламәтлегенең иминлеген тәэмин итәрлек чаралар билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри сертификацияләнергә тиеш. Мәҗбүри сертификацияләнергә тиеш товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) исемлеге законнары билгеләгән тәр-

типтә раслана.

Мәҗбүри сертификация узганлыгы турында мәгълүматы булмаган һәм әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән таләпләр нигезендә билгеләнгән тәртиптә тамга салынмаган (маркировкаланмаган) товар сату (эш башкару, хезмәт күрсәтү) рөхсәт ителми.

5. Әгәр кулланучы товарны (эшне) куллануның, саклауның яисә транспортлауның билгеләнгән кагыйдәләрен үтәп тә, товарны (эшне) куллану аның гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зарар китерүе ачыкланса, әзерләүче (башкаручы, сатучы), зарар китерү сәбәпләре бетерелгәнче, аны җитештерүне (сатуны) кичекмәстән туктатып торырга, ә кирәк очракларда аны әйләнештән төшереп калдыру чараларын күрергә яисә кулланучыдан (кулланучылардан) чакыртып алу гамәлләрен башкарырга тиеш.

Әгәр китерелгән зарарны бетерү мөмкин булмаса, әзерләүче (башкаручы) мондый товарны (эшне, хезмәт күрсәтүне) җитештерүдән төшереп калдырырга тиеш.

Әзерләүче (башкаручы) әлеге бурычын үтәмәгәндә, товарны (эшне, хезмәт күрсәтүне) җитештерүдән төшереп калдыру, әйләнештән чыгару һәм кулланучыдан чакыртып алу Татарстан Республикасының Кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт комитеты һәм товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфатын һәм хәвефсезлеген тикшереп торучы территория (район, шәһәр) комитетлары күрсәтмәләре буенча гамәлгә ашырыла.

Товарны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) чакыртып алу белән бәйле рәвештә кулланучыга китерелгән зыян әзерләүче (башкаручы) тарафыннан тулысынча капланырга тиеш.

6. Әгәр сатучының (башкаручының) кулланучылар гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә куркыныч тудырырлык товарлар сатуы (эш башкаруы) ачыкланса, мондый товарлар (эшләр) законда билгеләнгән тәртиптә сатучыдан (башкаручыдан) тартып алынырга тиеш.

**15 статья.** Сатучының (әзерләүченең, башкаручының) кулланучылар хокукларын бозган өчен җаваплылыгы

1. Кулланучылар хокукларын бозган өчен сатучы (әзерләүче, башкаручы) законда яисә шартнамәдә каралганча җаваплы була.

2. Кулланучыга китерелгән зыян неустойкадан (пенядан) тыш

әлеге Законда яисә шартнамәдә билгеләнгәнчә тулы күләмдә каплана.

3. Неустойканы (пеняны) түләү һәм зыянны каплау сатучыны (әзерләүчене, башкаручыны) кулланучы алдындагы йөкләмәләрен натуралата үтәүдән азат итми.

4. Сатучы (әзерләүче, башкаручы) үзенә йөкләнгән бурычны үти алмавы яисә тиешенчә үти алмавы хәл итмәслек сәбәпләр аркасында, шулай ук әлеге Законда каралган башка сәбәпләр аркасында килеп чыкканлыгын исбатлый алса, алар йөкләмәләрне үти алмаган өчен яисә тиешенчә үти алмаган өчен куела торган җаваплылыктан азат ителәләр.

5. Әлеге Законда яисә шартнамәдә каралган неустойканы (пеняны) түләү турында кулланучы таләпләрен сатучы (әзерләүче, башкаручы) ирекле рәвештә канәгатьләндерергә тиеш.

6. Суд кулланучының әлеге Закон билгеләгән таләбен канәгатьләндергәндә, суд кулланучы хокукын бозган сатучыдан (әзерләүчедән, башкаручыдан) кулланучының таләбен ирекле тәртиптә үтәмәгән өчен дәгъва бәясе күләмендә Татарстан Республикасының Республика бюджетына җибәрелүче штраф түләттерү турында карар кабул итәргә хаклы.

Әгәр кулланучы хокукларын яклап гариза белән кулланучыларның иҗтимагый берләшмәләренә (аларның ассоциацияләре, берлекләренә) мөрәҗәгать итсә,түләтелгән штрафның илле проценты шушы иҗтимагый берләшмәләргә (аларның ассоциацияләренә, берлекләренә) күчерелә.

<u>16 статья.</u> Товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) җитешсезлекләре аркасында китерелгән зыян өчен мөлкәти җаваплылык

1. Товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) конструктив, җитештерүчән, рецептур яисә башка төрле җитешсезлекләре аркасында кулланучы гомеренә, сәламәтлегенә яисә мөлкәтенә китерелгән зарар тулысынча түләттерелә.

2. Товарның (эшнең, хезмәт күрсәтүнең) җитешсезлекләре аркасында китерелгән зарарны түләттерүне таләп итү хокукы, сатучы (әзерләүче) белән шартнамә мөнәсәбәтләрендә булуына яисә булмавына карамастан, һәр зарар күрүчегә хас.

3. Товарның (эшнең) билгеләнгән хезмәт итү чоры яисә яраклылык чорында кулланучы гомеренә, сәламәтлегенә яисә мөлкәтенә китерелгән зарар түләтелергә тиеш.

Әгәр товарга (эшкә) карата әлеге Закон нигезендә әзерләүче (башкаручы) тарафыннан хезмәт итү чоры яисә яраклылык чоры билгеләнергә тиеш булып та, билгеләнмәгән булса йә товар сатып алган (эш башкарттырган) кулланучыга хезмәт итү чоры яки яраклылык чоры узгач ни эшләргә тиешлеге турында һәм бу гамәлләрне кылмау нинди нәтиҗәләргә китерүе хакында хәбәр ителмәгән очракта, зарар, китерелү вакытына карамастан, түләтелергә тиеш.

Әгәр әлеге Законның 12 статьясындагы 1 пункт нигезендә әзерләүче (башкаручы) товарга (эшкә) хезмәт итү чорын билгеләмәгән булса, товар (эш) кулланучыга тапшырылган көннән алып ун ел дәвамында китерелгән зарар түләтелә, әгәр шушы көнне билгеләү мөмкин булмаса, товар әзерләнгән (эш башкарылган) көннән алып китерелгән зарар түләтелә.

Зарар күрүче теләге буенча товарның җитешсезлекләре аркасында китерелгән зарар сатучыдан яисә әзерләүчедән түләтелә.

Эшнең яисә хезмәт күрсәтүнең җитешсезлекләре аркасында китерелгән зарар башкаручыдан түләтелә.

4. Фәнни һәм техник белемнәр дәрәҗәсенең товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) үзенчәлекле сыйфатларын ачарга мөмкинлек бирү-бирмәвенә бәйсез рәвештә, товарлар җитештерү (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) өчен кирәкле материаллар, җайланмалар, кораллар һәм башка чаралар куллану белән бәйле рәвештә кулланучы гомеренә, сәламәтлегенә яисә мөлкәтенә китерелгән зарар өчен әзерләүче (башкаручы) җаваплы була.

5. Әзерләүче (башкаручы, сатучы) зарарның хәл ителмәслек сәбәпләр аркасында яки кулланучының товарны (эшне, хезмәт күрсәтүне) куллануның, саклауның һәм транспортлауның билгеләнгән кагыйдәләрен бозуы аркасында китерелүен исбатлый алса, ул китерелгән зарар өчен җаваплылыктан азат ителә.

<u>17 статья.</u> Мораль зарар өчен компенсация

Әзерләүче (башкаручы, сатучы) яисә әзерләүче (сатучы) белән төзелгән шартнамә нигезендә аның вазыйфаларын үтәүче оешма кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга

салучы законнарда һәм норматив-хокукый актларда каралган кулланучылар хокукларын бозу аркасында китерелгән мораль зарар аның гаебе булган очракларда компенсацияләнергә тиеш. Мораль зарарның компенсацияләү күләме суд тарафыннан билгеләнә.

18 статья. Кулланучы хокукларын кысучы шартнамә шартларының гамәлгә яраксызлыгы

1. Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендәге законнарда яисә башка норматив-хокукый актларда билгеләнгән кагыйдәләр белән чагыштыргандагыга караганда кулланучыларның хокукларын кысучы шартнамә шартлары гамәлгә яраксыз дип таныла.

Әгәр кулланучы хокукларын кысучы шартнамәнең үтәлеше аркасында аңа зыян китерелсә, шушы зыян тулысынча әзерләүчедән (башкаручыдан, сатучыдан) түләттерелә.

2. Берәр төрле товарны (эшне, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алганда икенче бер төрле товарны (эшне, хезмәт күрсәтүләрне) сатып алуны шарт итеп кую тыела. Кулланучыны товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) ирекле сайлап алу хокукыннан мәхрүм итү аркасында аңа китерелгән зыян сатучыдан (башкаручыдан) тулысынча түләтелергә тиеш.

3. Сатучы (әзерләүче) кулланучыга аның ризалыгыннан башка бүтән төр түләүле өстәмә хезмәтләр күрсәтмәскә тиеш. Кулланучы үзенең ризалыгыннан башка түләүле өстәмә хезмәтләр күрсәтелгән өчен бирелгән акчасын сатучыдан (әзерләүчедән) кире сорап алырга хаклы.

19 статья. Кулланучыларның хокукларын суд аша яклау

1. Кулланучыларның хокукларын яклау федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә суд тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Дәгъвалар кулланучы теләге нигезендә йә дәгъвачының

яшәү урыны буенча, йә җавап тотучының урнашкан җире яисә зыян китерелгән урын буенча судка тапшырыла.

3. Кулланучылар үз хокукларын бозу белән бәйле дәгъвалар буенча, кулланучыларның җәмәгать берләшмәләре кулланучы, кулланучылар төркеме, кулланучыларның билгесез даирәсе мәнфәгатьләрендәге дәгъвалар буенча дәүләт пошлинасы түләүдән азат ителәләр.

4. Дәүләт һәм җәмәгать оешмалары мәнфәгатьләрен, шулай ук башка затларның закон тарафыннан расланган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклап гомуми вәкаләттәге һәм арбитраж судларына мөрәҗәгать иткәндә, Кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, аның территория (район, шәһәр) комитетлары, дәүләт хакимиятенең җирле органнары дәүләт пошлинасын түләүдән федераль законнар нигезендә азат ителәләр.

## 2 бүлек. Товарларны кулланучыларга сатканда кулланучыларның хокукларын яклау

### <u>20 статья.</u> Сыйфатсыз товар сату нәтиҗәләре

1. Сыйфатсыз товар сатып алган кулланучы, әгәр шушы товар сыйфаты турында килешенмәгән булса, үзе теләгәнчә түбәндәгеләрне таләп итәргә хаклы:

товарның җитешсезлекләрен бушлай төзәттерүне яисә кулланучы йә өченче зат шушы җитешсезлекләрне төзәттерүгә тоткан чыгымнарны түләтүне;

җитешсезлеккә тәңгәл рәвештә сатып алу хакын киметүне;

товарны шундый ук маркадагысына (модельдәгесенә, артикулдагысына) алмаштырып алуны;

сатып алу хакын яңадан санатып, товарны башка маркадагысына (модельдәгесенә, артикулдагысына) алмаштырып алуны;

сату-алу килешүен өзүне. Бу очракта кулланучы җитешсезлекләре булган товарны кире кайтарып бирергә тиеш.

Бу очракта кулланучы сыйфатсыз товар сатып алу аркасында үзенә китерелгән зыянны тулысынча түләтергә хаклы. Зыян кулланучының тиешле таләпләрен канәгатьләндерү өчен федераль законнарда һәм әлеге Законда күрсәтелгән вакыт эчендә түләнергә тиеш.

Техник яктан катлаулы товарларга карата әлеге пунктның дүртенче - алтынчы абзацларында күрсәтелгән кулланучы таләпләре, товарның җитешсезлекләре ачылганда, канәгатьләндерелергә тиеш. Мондый товарларның исемлеге федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә расланә.

Сатучы товарларны киләчәктә сатып җибәрү өчен комиссия шартнамәсе нигезендә сатып алган булса, кулланучының әлеге пунктның икенче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән таләпләре сатучы ризалыгы белән канәгатьләндерелергә тиеш.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән таләпләр кулланучы тарафыннан сатучыга яисә аның белән төзелгән шартнамә нигезендә сатучы вазыйфаларын үтәүче оешмага белдерелә.

3. Кулланучы әлеге статьяның 1 пунктындагы икенче һәм дүртенче абзацларда күрсәтелгән таләпләрне әзерләүчегә һәм аның белән төзелгән шартнамә нигезендә әзерләүче вазыйфаларын үтәүче оешмага белдерергә хаклы. Әлеге таләпләрне белдерү урынына кулланучы сыйфатсыз товарны әзерләүчегә кире кайтарырга һәм аның өчен түләнгән акчаны сорап алырга хаклы.

4. Гамәлгә яраклылык чоры билгеләнгән сыйфатсыз товарны кулланучы сатып алган очракта сатучы шушы товарны сыйфатлы товарга алмаштырып бирергә яисә аның өчен түләнгән товарны сорап алырга хаклы, әмма товарның җитешсезлеге гамәлгә яраклылык чоры чикләрендә ачыкланган булырга тиеш.

5. Кулланучы таләпләре ул товар яисә касса чегы күрсәткәннән соң, ә гарантия чоры билгеләнгән товарларга карата техник паспорт яисә аны алыштыручы башка документ күрсәткәннән соң карала.

Сатучы кулланучыга товар чегы яисә товарны сатып алу фактын таныклаучы башка берәр документ бирергә тиеш. Товар чегы яисә башка документ булмау кулланучыны тиешле таләпләре белән сатучыга мөрәҗәгать итүдән мәхрүм итми. Бу очракта сатып алу фактын яисә килешү гамәленең башка шартларын раслау өчен шаһитларның таныклаулары рөхсәт ителә.

Сатучы (әзерләүче) яисә аның белән төзелгән шартнамә буенча сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма товарның сыйфатын үз исәбеннән тикшерергә тиеш. Кулланучы товарның сыйфатын тикшергәндә катнашырга хаклы.

Товарның җитешсезлекләре барлыкка килүнең сәбәпләре ха-

кында бәхәс килеп чыкканда, сатучы (әзерләүче) яисә аның белән төзелгән шартнамә нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма үз исәпләреннән товарга экспертиза үткәрергә һәм кулланучыга аның урыны һәм вакыты турында хәбәр итәргә тиеш. Кулланучы мондый экспертизаның бәяләмәсенә суд тәртибендә шикаять белдерергә хаклы.

Әгәр товарга үткәрелгән экспертиза нәтиҗәсендә кулланучының үзенә тапшырылганнан соң товарны куллануның, саклауның яисә транспортлауның билгеләнгән кагыйдәләрен үтәмәве, өченче затларның гамәлләре яисә хәл ителмәслек сәбәпләр аркасында җитешсезлекләр килеп чыгуы ачыкланса, кулланучы товарга үткәрелгән экспертиза чыгымнарын, шулай ук аны үткәрү белән бәйле рәвештә товарны саклау һәм транспортлау чыгымнарын сатучыга (әзерләүчегә) яисә аның белән төзелгән шартнамә буенча сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешмага кире кайтарырга тиеш.

Кулланучылар товарның җитешсезлекләре үзләренә тапшырылганнан соң товарны куллануның, саклауның яисә транспортлауның билгеләнгән кагыйдәләрен үтәмәүләр, өченче затларның гамәлләре яисә хәл итмәслек сәбәпләр аркасында килеп чыкмауларын исбатлый алсалар, сатучы (әзерләүче) яисә сатучы (әзерләүче) белән төзелгән шартнамә нигезендә аның вазыйфаларын башкаручы оешма кулланучы таләпләрен канәгатьләндерергә тиеш.

6. Эре габаритлы товарны һәм биш килограммнан артыграк товарны ремонтка, бәясен төшерү, алмаштыру һәм кулланучыга кире кайтарып бирү сатучы (әзерләүче) яисә аның белән төзелгән шартнамә нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма исәбеннән һәм алар көче белән гамәлгә ашырыла. Бу йөкләмә үтәлмәгән очракта, шулай ук сатучы (әзерләүче) яисә аның белән төзелгән шартнамә нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма булмаганда, кулланучы үзе урнашкан җиргә шушы товарларны үзе китерә һәм кире алып китә. Бу вакытта сатучы (әзерләүче) яисә аның белән төзелгән шартнамә нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма кулланучының шушы товарларны китерү һәм кире алып китү белән бәйле чыгымнарын түли.

21 статья. Товарның җитешсезлекләренә карата кулланучы таләпләрен кую чоры

1. Әлеге Законның 12 статьясы нигезендә әзерләүче билгеләгән гарантия чоры яисә яраклылык чоры дәвамында товарның җитешсезлекләре ачылса, кулланучы товар җитешсезлекләренә әлеге Законның 20 статьясында билгеләнгән таләпләрне куярга хаклы.

Гарантия чорлары яисә яраклылык чорлары билгеләнмәгән товарларның җитешсезлекләре кулланучы товарны сатып алганнан соң алты ай эчендә ачыкланса, ә күчерелми торган мөлкәт җитешсезлекләре сатып алганнан соң ике елдан да артыграк булмаган вакыт эчендә ачыкланса һәм законда яисә шартнамәдә күбрәк вакыт билгеләнмәгән булса, кулланучы шушы таләпләрне куярга хаклы.

2. Товарның гарантия чоры, шулай ук хезмәт итү чоры кулланучыга товар сатылган көннән исәпләнә. Әгәр товарны сату көнен билгеләү мөмкин булмаса, бу чор товарны әзерләү көненнән исәпләнә.

Сезонлы товарлар (аяк киемнәре, кием-салым һәм башкалар) өчен бу чорлар тиешле сезон җиткән мизгелдән исәпләнә, ә мондый сезонның җитү вакыты кулланучы яшәүче урынның климат шартларыннан чыгып, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Товарларны үрнәкләре буенча, почта аша сатып җибәргәндә, шулай ук сату-алу шартнамәсе төзелгән мизгел белән товарны кулланучыга тапшыру мизгеле туры килмәсә, бу чор товарны кулланучыга китереп җиткерү көненнән исәпләнә, әгәр дә инде товарны махсус куярга (тоташтырырга) яисә җыярга кирәк булса, аны куйган (тоташтырган) яисә җыйган көннән бу чор исәпләнә. Әгәр кую (тоташтыру) яисә җыю көнен билгеләү мөмкин булмаса, бу чор сату-алу шартнамәсе төзелгән көннән исәпләнә.

Күчерелми торган мөлкәткә карата гарантия чоры һәм хезмәт итү чоры күчерелми торган мөлкәтне сату-алу турындагы шартнамәне дәүләт тарафыннан теркәү мизгеленнән исәпләнә.

Товарның яраклылык чоры товарны әзерләгән көннән соң товар куллануга яраклы булган дәвер белән йә товар куллануга яраксызга әверелгән көн җитү белән билгеләнә.

Товарның яраклылык чорының озынлыгы товарның стандартлар-

да билгеләнгән хәвефсезлек таләпләренә туры килергә тиеш.

3. Гарантия чорлары төп товарның комплектлаучы әйберләренә һәм состав өлешләренә билгеләнергә мөмкин. Комплектлаучы әйберләргә һәм состав өлешләренә гарантия чоры төп товарга исәпләнгән рәвештә үк исәпләп чыгарыла.

Төп товарның комплектлаучы әйберләренә һәм состав өлешләренә гарантия чоры төп товарның гарантия чорыннан әзрәк була алмый.

Әгәр комплектлаучы әйбергә төп товарныкыннан озаграк гарантия чоры билгеләнсә, комплектлаучы әйбернең җитешсезлеге шунда билгеләнгән гарантия чоры дәвамында мәгълүм булса, төп товарның гарантия чоры узуга карамастан, кулланучы товарның җитешсезлекләренә карата таләпләр куярга хаклы.

4. Әлеге статьяда күрсәтелгән чорлар шушы Законның 8 статьясы нигезендә кулланучыга бирелүче товар турындагы белешмәдә кулланучыга җиткерелә.

5. Товарның әзерләүче гаебе белән җибәрелгән асылый җитешсезлекләре ачыкланса, товарга әзерләүче билгеләгән гарантия чоры дәвамында яисә әлеге статьяның 1 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән гарантия чоры дәвамында кулланучы товарның җитешсезлекләрен бушлай бетерттерү таләбе белән әзерләүчегә мөрәҗәгать итәргә хаклы. Шушы таләп товарның билгеләнгән хезмәт итү чоры дәвамында яисә, товарга хезмәт итү чоры билгеләнмәгән булса, товар тапшырылганнан соң ун ел дәвамында белдерелергә мөмкин.

Әгәр әлеге таләп кулланучы мондый таләп куйганнан соң егерме көн эчендә канәгатьләндерелмәсә, кулланучы әзерләүчегә әлеге Законның 20 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән башка таләпләрне үзе теләгәнчә куярга мөмкин.

<u>22 статья.</u> Әзерләүченең (сатучының) товарның җитешсезлекләрен бетерүе

1. Товарның мәгълүм булган җитешсезлекләрен кулланучы шушы җитешсезлекләрне бетерү турындагы таләп белән мөрәҗәгать иткәннән соң егерме көн эчендә әзерләүче (сатучы) яисә аның белән төзелгән шартнамә нигезендә әзерләүче (сатучы) вазыйфаларын башкаручы оешма бетерә.

2.Озак куллану өчен әзерләнгән товарларга карата әзерләүче (сатучы) яисә аның белән төзелгән шартнамә нигезендә әзерләүче (сатучы) вазыйфаларын башкаручы оешма кулланучы әлеге таләпне куйганнан соң җиде көн эчендә товарны ремонтлаган вакыт аралыгында кулланып тору өчен кулланучыга шундый ук товарны бушлай бирергә, аны үз хисабына илтергә тиеш. Әлеге таләпләр кагылмый торган озак кулланылыш товарларының исемлеген федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

3. Товарның җитешсезлекләрен бетергән очракта, гарантия чоры товар кулланылмаган чорга озынайтыла. Бу вакыт кулланучы товарның җитешсезлекләрен бетерү белән мөрәҗәгать иткән көннән алып, ремонты тәмамланып, кулланучыга бирелгән көнгә кадәр исәпләнелә.

4. Товарның җитешсезлекләре төп товарның гарантия чорлары билгеләнгән комплектлаучы әйберен яисә состав өлешен алмаштыру юлы белән башкарылса, төп товарның яңа комплектлаучы әйберенә яисә состав өлешенә билгеләнүче гарантия чоры товарны, ремонтлап бетереп, кулланучыга тапшырган көннән исәпләнә.

<u>23 статья.</u> Сыйфатсыз товарны алмаштыру

1. Кулланучы товарның җитешсезлекләрен ачкан һәм мондый товарны алмаштыру турындагы таләбен белдергән очракта, сатучы (әзерләүче) яисә аның белән килешү нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма кулланучы тарафыннан әлеге таләпләр белдерелгәннән соң җиде көн эчендә мондый товарны алмаштырырга тиеш, ә кирәк чакта мондый товарга өстәмә тикшерү әлеге таләп белдерелгән көннән соң егерме көн эчендә сатучы (әзерләүче) яисә аның белән килешү нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы тарафыннан өстәмә рәвештә тикшерелергә тиеш.

Сатучының (әзерләүченең) яисә аның белән килешү нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешманың кулланучы таләп куйган көнгә алмаштыру өчен кирәкле товары булмаса, сатучы (әзерләүче) яисә аның белән килешү нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма мондый товарны таләп белдерелгәннән соң бер ай эчендә алмаштырырга тиеш. Кулланучы таләбе буенча сатучы (әзерләүче) яисә аның белән килешү ниге-

284



гендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма товарны алмаштыру чорында вакытлыча кулланып тору өчен кулланучыга үз исәбеннән шундый ук товар биреп торырга тиеш. Әлеге Законның 22 статьясындагы 2 пунктында билгеләнгән исемлектәге товарларга бу кагыйдә кагылмый.

2. Сыйфатсыз товар яңа, ягъни элек кулланылмаган товарга алмаштырылырга тиеш.

Товар алмаштырылганда гарантия чоры кулланучыга товар тапшырылган көннән исәпләнелә.

24 статья. Кулланучының аерым таләпләрен канәгатьләндерү вакытлары

Товарның сатылу бәясен нисбәти дәрәҗәдә киметү турында, товарның җитешсезлекләрен бетерү буенча кулланучы яисә өченче зат түккән чыгымнарны түләтү хакында, шулай ук кулланучыга сату-алу шартнамәсен өзү нәтиҗәсендә китерелгән зыяннарны (әзерләнүчегә сыйфатсыз товарны кире кайтарып бирү) түләтү турында кулланучының таләпләре тиешле таләп белдерелгәннән соң ун көн эчендә сатучы (әзерләүче) яисә аның белән төзелгән шартнамә нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма тарафыннан канәгатьләндерелергә тиеш.

25 статья. Кулланучының таләпләрен вакытында үтәмәгән өчен сатучы (әзерләүче) җаваплылыгы

1. Әлеге Законның 22,23 һәм 24 статьяларында каралган вакытларны бозган өчен, шулай ук товарга ремонт ясаган ( аны алмаштырган) вакытка кулланучының шундый ук товар бирүләрен таләп итүен үтәмәгән (үтәүне тоткарлаган) өчен сатучы (әзерләүче) яисә аның белән төзелгән шартнамә нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма кичектерелгән һәр көн өчен кулланучыга товар бәясенең бер проценты күләмендә неустойка (пеня) түли.

Товарның бәясе, сатучы (әзерлеүче) яисә аның белән килешү нигезендә сатучы (әзерләүче) вазыйфаларын башкаручы оешма тарафыннан кулланучының таләбе үтәлергә тиешле урындагы бәядән чыгып, әлеге таләп ирекле рәвештә үтәлгән көннән яисә, ул

ирекле үтәлмәгәндә, суд карары чыгарылган көннән билгеләнә.

2. Кулланучының таләпләре әлеге Законның 22 - 24 статьяларында каралган вакытларда үтәлмәгәндә, кулланучы әлеге Законның 21 статьясында билгеләнгән башка таләпләрне үзе теләгәнчә куя ала.

26 статья. Сыйфатсыз товар сатып алынган очракта кулланучы белән исәп-хисап ясау

1. Сыйфатсыз товарны шундый ук маркалы (модельле, артикуллы) товарга алмаштырганда товар бәясенә кабат исәп-хисап ясалмый.

2. Сыйфатсыз товарны башка маркалы (модельле, артикуллы) шундый ук товарга алмаштырганда, әгәр алмаштырылучы товарның бәясе аның урынына бирелүче товар бәясенә караганда түбәнрәк булса, кулланучы бәяләр арасындагы аерманы түләргә тиеш; әгәр алмаштырылучы товарның бәясе аның урынына бирелүче товар бәясенә караганда артыграк булса, бәяләр арасындагы аерма кулланучыга кайтарып бирелә. Алмаштырылучы товарның бәясе арткан очракта, аның кулланучы таләп куйган көндәге бәясе буенча, ә бәясе төшкән очракта - кулланучы сатып алган көндәге бәясе буенча исәп-хисап ясала.

3. Сату-алу шартнамәсе өзгәндә яисә сыйфатсыз товарны әзерләүчегә кайтарып биргәндә, йә сатып алу бәясен киметү турында кулланучы таләбен үтәгәндә, әгәр товар бәясе арткан булса, сату-алу шартнамәсен өзү яисә сыйфатсыз товарны әзерләүчегә кайтарып бирү, йә сатып алу бәясен киметү буенча кулланучы таләбен үтәгән көндәге бәядән чыгып исәп-хисап ясала, ә товар бәясе кимetелгән очракта - аны сатып алган көндәге бәядән чыгып ясала.

4. Кредитка товар сатып алган кулланучылар белән төзелгән сату-алу шартнамәсен өзгән очракта, аларга кредит товарын кайтарып биргән көнгә кадәр товар өчен түләнгән акчалата сумма кире кайтарып бирелә, шулай ук кредит биргән өчен түләнгән акча да кире кайтарыла.

27 статья. Кулланучының тиешле сыйфатлы товар алмаштырып алуга хокукы

1. Азык-төлектән булмаган сатып алган товарының рәвеше, аурлыгы, фасоны, төсе, күләме туры килмичә яисә башка сәбәпләр аркасында кулланучы аны тиешле урында файдалана алмаса, ул алган сатучыдан әлеге товарны тиешле сыйфатлы шундый ук товарга алмаштырып алырга хаклы.

Кулланучы азык-төлектән булмаган тиешле сыйфатлы товарны, сатып алган көнен исәпкә алмыйча, ундүрт көн эчендә алмаштыра ала.

Әгәр азык-төлектән булмаган тиешле сыйфатлы товар сатып алынганнан соң кулланылмаган булса һәм аның товар рәвеше, куллану үзенчәлекләре, пломбалары, фабрика ярлыклары, шулай ук сатып алынган товар белән бергә кулланучыга бирелгән товар чегы яисә касса чегы сакланган булса гына, әлеге товарны алмаштырырга мөмкин.

Әлеге статьяда күрсәтелгән нигезләрдә алмаштырылмый торган товарларның исемлеге законнарда билгеләнгән тәртиптә раслана.

2. Әгәр кулланучы сатучыга мөрәҗәгать иткән көнне сатуда андый товар булмаса, кулланучы, үзе теләп, сату-алу шартнамәсен өзә ала һәм товар өчен түләнгән акчаны кире кайтарып бирүне таләп итәргә яисә, сатуда тиешле товар барлыкка килгәч,аны шундый ук товарга алмаштырып алырга хаклы. Азык-төлектән булмаган сыйфатсыз товарны алмаштыруны таләп итүче кулланучыга тиешле сыйфатлы шундый ук товарның сатуда барлыкка килүе турында сатучы хәбәр итәргә тиеш.

28 статья. Аерым төр сату-алу шартнамәләренең кагыйдәләре

Аерым төр сату-алу шартнамәләренең кагыйдәләре, шулай ук кайбер аерым төр товарларны сату кагыйдәләре федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә раслана.

3 бүлек. Эшләр башкарганда (хезмәт күрсәткәндә) кулланучыларның хокукларын яклау

<u>29 статья.</u> Эшләр башкаруның (хезмәт күрсәтүләрнең) вакытлары

1. Башкаручы эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) аерым төр эшләрне (аерым төр хезмәт күрсәтүләрне) башкару кагыйдәләрендә яисә эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару турындагы шартнамәдә билгеләнгән вакытта башкарырга тиеш. Әгәр күрсәтелгән кагыйдәләрдә эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару вакыты билгеләнмәгән булса, эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару турындагы шартнамәдә ул күрсәтелергә мөмкин, шулай ук анда кагыйдәләрдә күрсәтелгәнгә караганда азрак вакыт та билгеләнергә мөмкин.

2. Эш башкару (хезмәт күрсәтү) вакыты эшне ( хезмәт күрсәтүне) тәгәлләү датасы (чоры) белән яисә (һәм) башкаручының эшкә (хезмәт күрсәтүгә) керешү датасы (чоры) белән билгеләнергә мөмкин. Эшләр башкару (хезмәт күрсәтүләр) турындагы шартнамә гамәлдә вакытта эш (хезмәт күрсәтү) өлешләп (көндәлек матбугат тарату, техник хезмәт күрсәтү) башкарылган очракта, эш башкаруның (хезмәт күрсәтүләрнең) аерым вакытлары ( чорлары) билгеләнергә тиеш.

<u>30 статья.</u> Эшләр башкару (хезмәт күрсәтү) вакытларының башкаручы тарафыннан бозылу нәтиҗәләре

1. Әгәр башкаручы үз вакытында эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) керешмәсә яисә эш башкару (хезмәт күрсәтү) барышында эш башкаруның (хезмәт күрсәтүнең) билгеләнгән вакытка тәгәлләнмәве ачыкланса, шулай ук эш башкару (хезмәт күрсәтү) вакытында үтәлмәгән очракта, кулланучы, үз сайлап, түбәндәгеләрне эшләргә хаклы:

эш башкару өчен яңа вакыт билгеләргә, шул вакыт эчендә эш башкаручы эшкә (хезмәт күрсәтүгә) керешергә һәм (яисә) эшне (хезмәт күрсәтүне) тәгәлләргә тиеш, эш башкару (хезмәт күрсәтү) бәясен киметүне таләп итәргә;

эш башкаруны (хезмәт күрсәтүне) акылга муафыйк бәягә өченче затларга тапшырырга яисә аны үз көче белән башкарырга һәм эш башкаручыдан тотылган чыгымнарны түләвен таләп итәргә;

эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне өзәргә;

Эш башкаруны (хезмәт күрсәтүне) башлау һәм (яисә) тәгәлләү вакытларын бозып китерелгән зыянны кулланучы тулысынча түләтергә хаклы. Зыян кулланучының тиешле таләпләрен канәгатьләндерү өчен билгеләнгән вакытларда түләтелә.

2. Эш башкаручыга эшне (хезмәт күрсәтүне) башлау һәм эшне (хезмәт күрсәтүне) тәгәлләү өчен кулланучы тарафыннан билгеләнгән яңа вакытлар эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәдә күрсәтелә.

Яңа вакытлар үтәлмәгәндә, кулланучы эш башкаручыга карата әлеге статьяның 1 пунктында билгеләнгән башка таләпләрне куя ала.

3. Эш башкару ( хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне өзгәндә, шулай ук башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) бәясен киметкәндә кулланучыга кайтарып бирелә торган башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәт) хакы әлеге Законның 26 статьясындагы 3 пункты нигезендә билгеләнә.

4. Башкаручы үз вакытында эш башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) керешмәгән очракта, яисә, эшне (хезмәт күрсәтүне) әкрен башкарып, аны билгеләнгән вакытка тәгәлләмәгән очракта эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамә өзелсә, башкаручы эш башкару (хезмәт күрсәтү) барышында тоткан үз чыгымнарын, шулай ук моңа кадәр башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәт) өчен түләүләрне кайтарып бирүне таләп итә алмый.

Кулланучы белән башкаручы арасында мондый очракларда исәп-хисап ясау тәртибенең үзенчәлекләре эшләрнең (хезмәт күрсәтүләрнең) аерым төрләрен башкару кагыйдәләре белән билгеләнергә мөмкин.

5. Эш башкаруны (хезмәт күрсәтүне) башлауның һәм тәгәлләүнең билгеләнгән вакытларын яисә әлеге статьяның 1 пункты нигезендә кулланучы тарафыннан билгеләнгән яңа вакытларын бозганда, башкаручы кулланучыга кичектерелгән һәр көн (әгәр вакыт сәгатьләрдә билгеләнгән булса, һәр сәгать) өчен - эш башкару (хезмәт күрсәтү) хакының өч проценты күләмендә, әгәр башкаруның (хезмәт күрсәтүнең) бәясе эшләр башкару (хезмәт күрсәтү-

лəр) турындагы шартнамəдə билгелəнмəгəн булса - заказның гомуми бəясеннəн өч процент күлəмендə неустойка (пеня) түли. Эшлəр башкару (хезмəт күрсəтүлəр) турында кулланучы белəн башкаручы арасында төзелгəн шартнамə тарафыннан неустойканың (пенядың) зуррак күлəме дə билгелəнергə мөмкин.

Эш башкаруга (хезмəт күрсəтүгə) керешү вакытларын бозган өчен неустойка (пеня) эш башкаруга (хезмəт күрсəтүгə) керешкəнчегə яисə кулланучы тарафыннан əлеге статьяның 1 пунктында каралган талəплəр куелганчыга кадəр кичектерелгəн һəр көн (əгəр вакыт сəгатьлəрдə билгелəнгəн булса, һəр сəгать) өчен алына.

Əгəр эш башкару (хезмəт күрсəтү) турындагы шартнамəдə аерым төр эш башкаруның (хезмəт күрсəтүнең) бəясе билгелəнмəгəн булса, кулланучы тарафыннан алынган неустойка (пеня) суммасы аерым төр эш башкаруның (хезмəт күрсəтүнең) бəясеннəн яисə заказның гомуми бəясеннəн артык була алмый.

Эш башкаруны (хезмəт күрсəтүне) тəгаллəү вакытларын бозган өчен неустойка (пеня) эш башкару (хезмəт күрсəтү) тəгаллəнгəнчегə кадəр яисə кулланучы тарафыннан əлеге статьяның 1 пунктында каралган талəплəр куелганчыга кадəр кичектерелгəн һəр көн (əгəр вакыт сəгатьлəрдə билгелəнгəн булса, һəр сəгать) өчен алына.

Неустойканың (пеняның) күлəме эш башкару (хезмəт күрсəтү) бəясеннəн чыгып билгелəнə, əгəр бу бəя билгелəнмəгəн булса, башкаручы тарафыннан ирекле рəвештə кулланучының талəбе үтəлəсе көндə һəм урында яисə, əгəр кулланучының талəбе ирекле рəвештə үтəлмəсə, суд карары чыгарылган көндə гамəлдə булган заказ бəясеннəн чыгып билгелəнə.

6. Эш башкару (хезмəт күрсəтү) вакытларының бозылуы аяныч хəллəр аркасында яисə кулланучы гаебе белəн килеп чыкканын башкаручы исбатлый алса, кулланучының əлеге статьяның 1 пунктында билгелəнгəн талəплəре үтəлми.

<u>31 статья.</u> Башкарылган эшнең (күрсəтелгəн хезмəтнең) кимчелеклəрен тапканда кулланучының хокуклары

1. Башкарылган эшнең (күрсəтелгəн хезмəтнең) кимчелеклəрен тапканда кулланучы үзе сайлап түбəндəгелəрне талəп итəргə

хаклы:

башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) кимчелекләрен түләүсез бетерүне;

башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) бәясен тиешенчә киметүне;

шул ук материалдан шундый ук сыйфатлы бүтән әйберне бушлай ясауны яисә эшне кабат башкаруны. Бу очракта кулланучы элек үзенә башкаручы тарафыннан бирелгән әйберне кайтарып бирергә тиеш;

башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) кимчелекләрен үз көче яисә өченче затлар көче белән бетергәндә тотылган чыгымнарны түләтүне.

Кулланучы, кимчелекләрне түләүсез бетерү, башка әйбер әзерләү яисә кабат эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы таләпләр белән бергә, башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) бәясен киметү турында да таләпләр куя ала.

Әгәр башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) кимчелекләре эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәдә билгеләнгән вакытта башкаручы тарафыннан бетерелмәсә, кулланучы әлеге шартнамәне өзә ала. Әгәр башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) кулланучы тарафыннан җитди кимчелекләре табылса яисә шартнамәдә куелган шартлардан шактый читкә тайпылу күренсә, кулланучы шулай ук эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне өзә ала.

Кулланучы башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) кимчелекләре аркасында үзенә китерелгән зыянны шулай ук тулысынча түләүне дә таләп итәргә хаклы. Зыян кулланучының тиешле таләпләрен үтәү өчен билгеләнгән вакытларда түләтелә.

2. Башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне өзгәндә кулланучыга кайтарылып бирелә торган хакы, шулай ук башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) бәясен киметкәндә исәпкә алына торган хакы әлеге Законның 26 статьясындагы 3 пункты нигезендә билгеләнә.

3. Әлеге статьяның 1 пунктында билгеләнгән таләпләр башкарылган эшне (күрсәтелгән хезмәтне) кабул иткәндә яисә эш башкару (хезмәт күрсәтү) барышында кимчелекләр табылган очракта куелырга мөмкин, ә башкарылган эшне (күрсәтелгән хезмәтне) кабул иткәндә кимчелекләрне табу мөмкинлеге булмаган очракта -

гарантия вакыты чыкканчы яисә, гарантия вакыты булмаганда, башкарылган эшне (күрсәтелгән хезмәтне) кабул иткән көннән башлап алты ай эчендә. Төзелгән корылмалардагы яисә күчерелми торган бүтән мөлкәттәге кимчелекләрне башкарылган эшне (күрсәтелгән хезмәтне) кабул иткәндә табу мөмкин булмаса, аларга карата таләпләр башкарылган эшнең ( күрсәтелгән хезмәтнең) гарантия вакыты чыкканчы кимчелекләр табылганда, ә гарантия вакыты булмаганда, башкарылган эшне (күрсәтелгән хезмәтне) кабул иткән көннән башлап ике ел дәвамында куелырга мөмкин.

4. Башкарылган эштә (күрсәтелгән хезмәттә) башкаручы тарафыннан ясалган җитди кимчелекләр ачыкланган очракта, кулланучы, башкарылган эшкә (күрсәтелгән хезмәткә) башкаручы билгеләгән гарантия вакыты чыккач яисә әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән вакытлар чыккач, башкарылган эштәге (күрсәтелгән хезмәттәге) кимчелекләрне бушлай бетерүне таләп итәргә хаклы. Кулланучының мондый таләбе башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) билгеләнгән хезмәт итү вакытында яисә, әгәр башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) хезмәт итү вакыты билгеләнмәгән булса, башкарылган эшне (күрсәтелгән хезмәтне) кабул иткән көннән башлап ун ел дәвамында куелырга мөмкин. Әгәр ул таләп әлеге Законның 32 статьясында билгеләнгән вакытларда үтәлмәсә, кулланучы үзе сайлап түбәндәгеләрне таләп итәргә хаклы:

башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәт) өчен бәяне тиешенчә киметүне;

башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) кимчелекләрен үз көче яисә өченче затлар көче белән бетергәндә тотылган чыгымнарны түләттерүне;

эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне өзүне һәм зыянны түләттерүне.

<u>32 статья.</u> Башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) кимчелекләрен бетерү вакытлары

Башкарылган эштә (күрсәтелгән хезмәттә) эш башкару (хезмәт күрсәтү) барышында табылган кимчелекләр кулланучы тарафыннан куелган муафыйкъ вакытларда бетерелергә тиеш.

Башкарылган эшне (күрсәтелгән хезмәтне) кабул иткәндә яклар шартнамәсе (килешүе) белән яисә аерым төр эшләр башкару

(эерым төр хезмәт күрсәтү) кагыйдәләре белән кыскарак вакыт билгеләнмәгән булса, башкарылган эшнең (күрсәтелгән хезмәтнең) кимчелекләре кулланучы тарафыннан таләп куелган көннән башлап егерме көн эчендә бетерелергә тиеш.

Кулланучы тарафыннан яисә яклар шартнамәсе (килешүе) белән билгеләнгән кимчелекләрне бетерү вакыты шартнамәдә яисә яклар имза сала торган бүтән документта күрсәтелә.

Башкарылган эштәге (күрсәтелгән хезмәттәге) кимчелекләрне бетерүнең әлеге статьяда каралган вакытларын бозган өчен башкаручы кулланучыга кичектерелгән һәр көн өчен неустойка (пеня) түли, аның күләме һәм аны исәпләү тәртибе әлеге Законның 30 статьясындагы 5 пункты нигезендә билгеләнә.

Күрсәтелгән вакытлар бозылган очракта, кулланучы башкаручыга карата әлеге Законның 31 статьясындагы 1 һәм 4 пунктларында каралган таләпләрне куярга хаклы.

<u>33 статья.</u> Кулланучының аерым таләпләрен канәгатьләндерү вакытлары

1. Башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәт өчен) бәяне киметү турында, башкарылган эштәге (күрсәтелгән хезмәттәге) кимчелекләрне үз көче яисә өченче затлар көче белән бетергәндә тотылган чыгымнарны түләтү турында, шулай ук эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне өзү аркасында китерелгән зыянны түләтү хакында кулланучының әлеге Законның 30 статьясындагы 1 пунктында һәм 31 статьясындагы 1 һәм 4 пунктларында каралган таләпләре тиешле таләп куелган көннән башлап ун көн эчендә үтәлергә тиеш.

2. Шундый ук материалдан шундый ук сыйфатлы яңа әйберне бушлай ясау турында яисә кабат эш башкару (хезмәт күрсәтү) турында кулланучының таләпләре ашыгыч рәвештә эш башкару (хезмәт күрсәтү) өчен билгеләнгән вакытта үтәлергә тиеш, әгәр мондый вакыт билгеләнмәгән булса, бу очракта эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы тиешенчә башкарылмаган шартнамәдә каралган вакытта үтәлергә тиеш.

3. Кулланучының аерым таләпләрен канәгатьләндерүнең әлеге статьяда каралган вакытларын бозган өчен башкаручы кулланучыга һәр кичектерелгән көн өчен неустойка (пеня) түли, аның күләме

һәм аны исәпләү тәртибе әлеге Законның 30 статьясындагы 5 пункты нигезендә билгеләнә. Әлеге статьяның 1 һәм 2 пунктларында билгеләнгән вакытларны бозган очракта, кулланучы башкаручыга карата шушы Законның 30 статьясындагы 1 пунктында һәм 31 статьясындагы 1 һәм 4 пунктларында каралган бүтән таләпләрне куярга хаклы.

34 статья. Кулланучының эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне өзү хокукы

Кулланучы, эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне өзү хакында хәбәр алганчыга кадәр башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәт) бәясенә тиң өлешне башкаручыга түләп, күрсәтелгән шартнамәнең теләсә кайсы вакытта өзәргә хаклы. Кулланучы шулай ук башкаручыга эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне өзү аркасында китерелгән зыянны да түләргә тиеш, бу сумма күрсәтелгән шартнамәне өзү турында хәбәр алганчыга кадәр башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәт) өчен түләнгән бәя белән тулысынча башкарылучы эшнең (күрсәтелүче хезмәтнең) бәясе арасындагы аерма чикләрендә була.

35 статья. Эш башкару (хезмәт күрсәтү) сметасы

1. Эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәдә каралган эшне башкару (хезмәтне күрсәтү) өчен төгәл яисә якынча смета төзелергә мөмкин.

Кулланучы яисә башкаручы таләбе буенча мондый сметаны төзү мәҗбүри.

2. Төгәл сметада каралмаган эшне башкаруга (хезмәт күрсәтүгә) кулланучы ризалык бирмәгән булса яисә башкаручыга андый эшне башкару (хезмәтне күрсәтү) йөкләнмәгән булса, башкаручы мондый эшне башкару (хезмәтне күрсәтү) өчен түләү һәм өстәмә чыгымнар таләп итә алмый.

Әгәр якынча сметаны арттыру зарурлыгы туса, башкаручы бу хакта кулланучыга кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта кулланучы, башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәт) өчен баштагы сметада билгеләнгән чыгымнарның тотылган кадәрен башкаручыга түләп, эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне үтәү-

дән баш тартырга хаклы. Әгәр башкаручы якынча сметаны арттыру турында кулланучыны кисәтмәгән булса, башкаручы баштагы якынча смета чикләрендә эш башкарырга (хезмәт күрсәтергә) тиеш.

36 статья. Башкаручы материалыннан эш башкару

1. Әгәр кулланучы эшне үз материалыннан башкаруны таләп итмәсә, башкаручы эш башкару турындагы шартнамәдә билгеләнгән эшне үз материалыннан һәм үз акчаларына башкарырга тиеш.

Үз материалыннан эш башкаручы ул материалның тиешле сыйфаты өчен җаваплы була.

2. Яклар килешүендә башкаручы материалы өчен исәп-хисап ясауның бүтән тәртибе каралмаган булса, шушы шартнамә тәгелгәндә кулланучы тарафыннан тулысынча яисә, башкарылган эшне кабул итеп алганда кулланучы тарафыннан тулысынча исәп-хисап ясалу шарты белән, аерым төр эшләрне башкару кагыйдәләрендә йә эш башкару турындагы шартнамәдә күрсәтелгән күләмдә түләнә.

3. Күрсәтелгән кагыйдәләрдә яисә эш башкару турындагы шартнамәдә каралган очракларда, материал башкаручы тарафыннан кулланучыга кредитка бирелергә мөмкин. Башкаручының кредитка бирелгән материалына бәя артканда, яңадан исәп-хисап ясалмый.

4. Башкаручының үз материалы һәм эш башкару өчен кирәкле техник чаралар, эш кораллары һәм башкалар эш башкару урынына башкаручы тарафыннан китерелә.

37 статья. Кулланучы материалыннан (әйберennән) эш башкару

1. Әгәр эш тулысынча йә өлешчә кулланучы материалыннан (әйберennән) башкарылса, башкаручы әлеге материалның (әйбернең) сакланышы һәм аның дөрес кулланылышы өчен җаваплы була.

Башкаручы :

кулланучы тарафыннан тапшырылган материалның (әйбернең) эшкә яраксызлыгы йә сыйфатсыз булуы хакында аны кисәтергә тиеш;

тотылган материал турында хисап бирергә һәм калганын кулланучыга кайтарырга тиеш.

Кулланучыдан алган материалны (әйберне) тулысынча йә

өлешчә югалтканда (зарарлаганда), башкаручы үз көче эчендә аны шундый ук сыйфаттагы бер үк материалга алмаштырырга һәм шундый ук материалдан (әйбердән) муафыйкъ вакыт эчендә кулланучы теләге буенча әйбер ясарга тиеш, ә шундый ук сыйфатлы бер үк материал (әйбер) булмаганда - кулланучыга югалган (зарарланган) материалның (әйбернең) икеләтелгән хакы, шулай ук кулланучы тоткан чыгымнар түләнергә тиеш.

2. Югалган (зарарланган) материалның (әйбернең) бәясе, башкаручы тарафыннан кулланучының таләбе ирекле рәвештә канәгатьләндерелергә тиешле урында булган материалның (әйбернең) шушы көндәге бәясеннән чыгып, яисә, әгәр кулланучының таләбе ирекле рәвештә канәгатьләндерелмәгән булса, хөкем карары чыгарылган көннән билгеләнә.

Башкаручыга тапшырылучы материалның (әйбернең) бәясе кулланучы тарафыннан билгеләнә һәм эш башкару турындагы шартнамәдә яисә аның түләнгән булуын раслаучы бүтән документта (квитанциядә, заказда) күрсәтелә.

3. Әгәр кулланучы материалның (әйбернең) тулысынча яисә өлешчә югалуын (зарарлануын) китереп чыгарырлык аерым үзенчәлекләре турында башкаручы тарафыннан кисәтелгән булса, башкаручы кулланучыдан алган материалның (әйбернең) тулысынча яисә өлешчә югалуы (зарарлануы) өчен җаваплылыктан азат ителә. Материалның (әйбернең) аерым үзенчәлекләрен белмәве башкаручыны җаваплылыктан азат итми.

<u>38 статья.</u> Башкарылучы эшнең (күрсәтелүче хезмәтнең) сыйфатына тәэсир итәрлек шартлар турында башкаручының кулланучыга хәбәр итәргә тиешлеге

Кулланучының күрсәтмәләрен үтәү һәм кулланучыга бәйле башка шартлар башкарылучы эшнең (күрсәтелүче хезмәтнең) сыйфатын төшерергә мөмкин булуы хакында башкаручы үз вакытында кулланучыга хәбәр итәргә тиеш.

Әгәр кулланучы, башкаручы тарафыннан вакытында һәм нигезле мәгълүмат алуга карамастан, эшкә яраксыз һәм сыйфатсыз материалын муафыйкъ вакытларда алыштырмаса, эш башкару (хезмәт күрсәтү) ысулы турындагы күрсәтмәләрне үзгәртмәсә яисә башкарылучы эшнең (күрсәтеләсе хезмәтнең) сыйфатын төшерерлек бүтән

шартларны бетермәсә, башкаручы эш башкару (хезмәт күрсәтү) турындагы шартнамәне әзәргә һәм зыянны тулысынча түләүне таләп итәргә хаклы.

39 статья. Башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәт) өчен исәп-хисап ясау тәртибе

Башкарылган эш (күрсәтелгән хезмәт) өчен исәп-хисап ясау тәртибе кулланучы һәм башкаручы арасында төзелгән шартнамә белән билгеләнә.

Әгәр Татарстан Республикасы законнарда яисә башка норматив-хокукый актларында яисә кулланучы белән башкаручы арасында төзелгән шартнамәдә башкасы билгеләнмәгән булса, башкаручы тарафыннан эш башкару (хезмәт күрсәтү) тәгәлләнгәч, кулланучы аның белән тулысынча исәп-хисап ясарга тиеш.

40 статья. Кулланучыларга көнкүреш хезмәте һәм башка төр хезмәт күрсәтүләрнең кагыйдәләре

Кулланучыларга көнкүреш хезмәте һәм башка төр хезмәт күрсәтүләрнең кагыйдәләре (аерым төр эшләр башкару кагыйдәләре һәм аерым төр хезмәт күрсәтү кагыйдәләре) Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

41 статья. Аерым төр хезмәт күрсәтүләрне җайга салу

Әгәр әлеге бүлек аерым төр хезмәт күрсәтүләр турындагы шартнамәләргә кагылмаса, мондый шартнамәләрнең шартларын бозу нәтиҗәләре закон белән билгеләнәләр.

4 бүлек. Кулланучыларның хокукларын дәүләт һәм җәмәгатьчелек яклавы

42 статья. Кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетының, аның территория (район, шәһәр) комитетларының вәкаләтләре

1. Кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Респуб-

ликасы дәүләт комитеты, аның территория (район, шәһәр) комитетлары кулланучыларның хокукларын яклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе законнарының һәм башка хокукый актларының үтәлешен дәүләт тикшереп торуын тәэмин итәләр.

Бу органнар түбәндәгеләрне җибәрәләр:

кулланучыларның әлеге Законда һәм башка хокукый актларда каралган хокукларын бозуны туктату турында әзерләүчеләргә (башкаручыларга, сатучыларга) үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр;

тиешле эшчәнлек башкару өчен алынган лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору турындагы яисә аны вакытыннан алда юкка чыгару хакындагы мәсьәләне хәл итү өчен шушы лицензияне биргән органга кулланучыларның хокуклары бозылу турында материаллар;

кулланучыларның законда каралган хокукларын бозуга бәйле җинаять билгеләре буенча җинаять эше ачу турындагы мәсьәләләрне хәл итү өчен прокуратура органнарына һәм бүтән хокук саклау органнарына материаллар.

2. Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, аның территория ( район, шәһәр) комитетлары, дәүләт идарәсенең вәкаләтле башка органнары белән бергәләп, товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфатын һәм хәвефсезлеген тикшереп торалар.

3. Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты дәүләт идарәсенең товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) хәвефсезлеген тикшереп торучы республика органнары белән хезмәттәшлек итә.

4 Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, аның территория (район, шәһәр) комитетлары Татарстан Республикасы территориясендә сатыла торган товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) бәяләр дисциплинасын, лицензияләү тәртибен, штрихлы кодлаштыру турындагы нигезләмәләрне, сәүдә итү һәм сертификацияләү кагыйдәләрен бозуны бетерү хакында күрсәтмәләр бирәләр.

5. Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, аның территория (район, шәһәр) комитетлары Татарстан Республикасы законнары нигезендә кулланучыларның хокукларын яклау өлкәсендә административ җаваплылыкка тарту турында карарлар чыгарырга хаклы.

6. Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнарына кабул ителгән үә актларында кулланучыларның хокукларын яклау турында гамәлдәге законнарның бозылуы турында материаллар җибәрә.

7. Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты ваклап сатуның, көнкүреш хезмәте күрсәтүнең, транспортның, туризм һәм башка хезмәт күрсәтүләрнең кайбер өлкәләре өчен, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең тиешле органнары белән килешеп, үрнәк шартнамәләр әзерләргә хаклы.

8. Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, аның территория (район, шәһәр) комитетлары кулланучыларның хокуклары бозылу турындагы шикаятьләрне карыйлар һәм кулланучыларның хокукларын яклау хакындагы законнарның бозылуын бетерү буенча күрелгән чаралар турында кулланучыларга язмача хәбәр итәләр.

9. Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты кулланучыларның хокукларын яклау өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы законнарны һәм башка хокукый актларны куллану мәсьәләләре буенча рәсми аңлатмалар бирә.

10. Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, аның территория органнары әзерләүчеләр (эш башкаручылар, сатучылар) белән эшкуарлык эйләнеше кагыйдәләрен һәм гадәтләрен кулланучыларның мәнфәгатьләреннән чыгып үтәү турында килешүләр төзи алалар.

11. Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, аның территория (район, шәһәр) комитетлары, кулланучыларның хокуклары бозылу ачылган очракларда кулланучыларның хокукларын яклап судка мөрәҗәгать итә алалар, кулланучы, кулланучылар теркеме һәм кулланучыларның билгесез даирәсе мәнфәгатьләрен кайгыртып, шул исәптән кулланучыларның законда яисә башка хокукый актта билгеләнгән хокукларын берничә мәртәбә йә тупас бозган өчен әзерләүчене (эш

башкаручыны, сатучыны) эшеннән алу яисә шәхси эшкуарның эшчәнлеген туктату турында судларга дәгъва белдерә алалар, шулай ук Закон нигезендә мәҗбүри штрафлар салу турында судларга дәгъва белдерә алалар.

43 статья. Әзерләүченең (эш башкаручының, сатучының) Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетына, аның территория (район, шәһәр) комитетларына мәгълүматлар бирү йөкләмәләре

Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, аның территория (район, шәһәр) комитетлары таләбе буенча әзерләүче (эш башкаручы, сатучы) ышанычлы документларны, аңлатмаларны һәм Кулланучыларның хокукларын яулау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетының, аның территория (район, шәһәр) комитетларының әлеге Законда каралган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәк булган бүтән мәгълүматны язмача яисә телдән алар билгеләгән вакытка бирергә тиеш.

44 статья. Товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфатын һәм хәвефсезлеген тикшереп торучы дәүләт идарәсенең республика органнары вәкаләтләре

1. Товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) хәвефсезлеген тәэмин итү максатларында, товарларның (эшләрнең,хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфатын һәм хәвефсезлеген тикшереп торучы стандартлаштыру, метрология һәм сертификацияләү буенча республика органнары, санитария-эпидемиология күзәтүе буенча республика органнары, әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау буенча республика органнары үз вәкаләтләре чикләрендә

түбәндәгеләрне башкаралар:

товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) хәвефсезлегенә карата куелган таләпләрнең үтәлешен тикшереп торалар;

товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) хәвефсезлегенә карата куелган таләпләрнең бозылуын бетерү буенча күрсәтмәләр җибәрәләр, андый товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) җитештерүдән төшереп калдыру, андый товарларны эшләп чыгаруны һәм сатуны (андый эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүне) туктату, куллануга яраклылык вакыты чыккан товарларны һәм куллануга яраклылык вакыты билгеләнергә тиеш булып та, билгеләнми калган товарларны (эшләрне) сатуны туктату турындагы таләпләрнең, шулай ук товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) турында ышанычлы һәм җитәрлек мәгълүмат булмаганда, товарлар сатуны (эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүне) туктатып тору турындагы, аларны кулланучылардан кире алу һәм кулланучыларга бу хакта хәбәр итү турындагы таләпләрнең бозылуын бетерү буенча күрсәтмәләр җибәрәләр;

әзерләүчеләр (эш башкаручылар, сатучылар) тарафыннан товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) хәвефсезлеге буенча таләпләр бозылган очракта, аларга карата судларга, арбитраж судларга дәгъва белдерәләр.

2. Товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) хәвефсезлеген тәэмин итү максатларында, товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфатын һәм хәвефсезлеген тикшереп торучы стандартлаштыру, метрология һәм сертификацияләү буенча республика органнары, санитария-эпидемиология күзәтүе буенча республика органнары, әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклау буенча республика органнары товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) хәвефсезлегенә карата үз вәкаләтләре чикләрендә мәҗбүри таләпләр билгелиләр һәм бу таләпләрнең үтәлешен тикшереп торалар.

3. Дәүләт идарәсенең товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфатын һәм хәвефсезлеген тикшереп тору буенча республика органнары эшчәнлеген җайга салу, шулай ук товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) карата мәҗбүри республика сертификациясе эшләрен оештыру һәм үздыру Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетына

йөкләнә.

45 статья. Дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан кулланучыларның хокукларын яклау

Кулланучыларның хокукларын яклау максатларында дәүләт идарәсенең җирле органнары, җирле үзидарә органнары түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга хаклы:

кулланучыларның шикаятьләрен карарга, аларга кулланучыларның хокукларын яклау мәсьәләләре буенча киңәшләр бирергә;

сатучылар (эш башкаручылар, әзерләүчеләр) белән кулланучылар арасында төзелә торган шартнамәләрне кулланучыларның хокукларын бозучы шартларны ачыклау максатларында карарга;

сыйфатсыз, шулай ук кулланучылар гомере, сәламәтлеге өчен һәм әйләнә-тирә мохит өчен хәвефле товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) ачыклаганда, әлеге товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфатын һәм хәвефсезлеген тикшереп торучы республика идарә органнарына бу хакта кичекмәстән хәбәр итәргә;

ышанычлы һәм җитәрлек мәгълүматы булмаган яисә куллануга яраклылык вакыты чыккан йә куллануга яраклылык вакыты билгеләнергә тиеш булып та, билгеләнми калган товарларны сату (эшләр башкару, хезмәт күрсәтү) ачыкланган очракларда, мәгълүмат бирелгәнче мондый товарлар сатуны (эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүне) туктатып торырга яки товарлар сатуны (эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүне) бөтенләй туктатырга;

кулланучыларның (кулланучыларның билгесез даирәсенең) хокукларын яклап, судларга мөрәҗәгать итәргә.

46 статья. Кулланучыларның иҗтимагый берләшмәләренең (аларның ассоциацияләренең, берлекләренең) хокуклары

1. Гражданнар ирекле рәвештә кулланучыларның иҗтимагый берләшмәләренә (аларның ассоциацияләренә, берлекләренә) берләшә алалар.

2. Кулланучыларның иҗтимагый берләшмәләре (аларның ассо-

циациялəре, берлеклəре) үзлəренең уставларында каралган очракларда түбəндəгелəрне гамəлгə ашырырга хаклы:

товарларның (эшлəрнең, хезмəт күрсəтүлəрнең) хəвефсезлегенə карата талəплəрне, шулай ук бу өлкəдə мəҗбүри талəплəрне билгелəүче стандартларны, кулланучыларның хокукларын яклау өлкəсендəге мөнəсəбəтлəрне җайга салучы Татарстан Республикасы законнары проектларын һəм башка хокукый актларын эзерлəүдə катнашырга;

товарларның (эшлəрнең, хезмəт күрсəтүлəрнең) сыйфатына һəм хəвефсезлегенə бəйсез экспертиза ясарга;

кулланучыларның хокуклары үтəлешен, сəүдə, көнкүреш һəм кулланучыларга башка төр хезмəт күрсəтү кагыйдəлəре үтəлешен тикшерергə, кулланучыларның хокукларын бозу фактлары буенча экспертиза үткəргəндə, кулланучыларның кушуы буенча шунда катнашырга;

товарларның (эшлəрнең, хезмəт күрсəтүлəрнең) сыйфатын яхшырту, кулланучыларның гомере, сəламəтлеге, мөлкəте өчен һəм əйлəнə-тирə мохит өчен хəвефле товарларны (эшлəрне, хезмəт күрсəтүлəрне) əйлəнештəн чыгару, җитештерүдəн төшереп калдыру чаралары турында Кулланучыларның хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дəүлəт комитетына, аның территория (район, шəһəр) комитетларына тəкъдимнəр кертергə;

товарларның (эшлəрнең, хезмəт күрсəтүлəрнең) хəвефсезлегенə һəм сыйфатына карата куелган талəплəргə туры килми торган товарлар чыгаруда һəм сатуда (эшлəр башкаруда, хезмəт күрсəтүдə) гаепле, шулай ук кулланучыларның Татарстан Республикасы законнарында һəм башка норматив-хокукый актларында билгелəнгəн хокукларын бозуда гаепле затларны җаваплылыкка тарту турында материалларны прокуратура органнарына, башка хокук саклау органнарына, шулай ук дəүлəт идарəсенең административ хокук бозулар турындагы эшлəрне карарга вəкалəтлəре булган органнарына кертергə;

дəүлəт хакимияте һəм идарəсе республика органнарының , дəүлəт хакимияте һəм идарəсе җирле органнарының, җирле үзидарə органнарының кулланучыларның хокукларын яклау өлкəсендəге мөнəсəбəтлəрне җайга салучы законнарга каршы килүче актларына карата протест белдерү өчен материаллар белəн, шулай ук кулланучылар базарында хокук бозуларга китерүче сəбəплəрне бетерү

303



чаралары күрү өчен мәгълүмат белән прокуратура органнарына мөрәҗәгать итәргә;

кулланучылар (кулланучыларның билгесез даирәсе) хокукларын яклап судларга мөрәҗәгать итәргә.

47 статья. Кулланучыларның билгесез даирәсе мәнфәгатьләрен яклау

Кулланучылар хокукларын яклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, кулланучыларның хокукларын яклау буенча район, шәһәр комитетлары һәм дәүләт идарәсенең товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) сыйфатын һәм хәвефсезлеген тикшереп торучы республика органнары, җирле үзидарә органнары, кулланучыларның иҗтимагый берләшмәләре (аларның ассоциацияләре, берлекләре) сатучыларның (әзерләүчеләрнең, эш башкаручыларның) яисә алар белән килешү нигезендә сатучылар (әзерләүчеләр) вазыйфаларын башкаручы оешмаларның кулланучыларның билгесез даирәсенә карата хокукка каршы гамәлләрен тану турында һәм бу гамәлләрне туктату турында судларга дәгъва белдерергә хаклы.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре, 2 июле
1997 елның
N 1245